

Бер кон ел туйдыра. Аграрийлар, башка һәрбер кеше кебек vк, бу фразанын мәгънәсен анлыйлар. Унышны жыю вакытында механикларнын һәм ком- байнчыларнын ял коннәре булмый диярлек иде - Мордовия авыл хужалыгы житештерvчеләре урып-жыю алып баралар. Быел аларга 475 мен гектардан артык мәйданда бортекле һәм кузаклы культураларны жыеп аласы бар. Бу чорга республика хужалыклары ныклап әзерләнделәр. Хәзер ин моһиме, һава торышы сынатмасын һәм, әлбәттә, техника. Тик кайбер районнарда биш кон янгыр явып торды, шуна игеннәрне сугу тукталып торган иде.      Мордовия кырларыннан жиде йоз мен тонна ашлык жыелды инде. «Мордовский бекон»да урып-жыюга оптимизм белән карыйлар. Предприятиедә быел козге бодай унышы буенча рекорд куела. Бу предприятиянен баш инженеры Николай Кемаев сойләвенчә, Зубов-Поляна районы басуларында гектардан 50 центнердан артык уныш жыеп алына. Ельник районы игенчеләре дә урып-жыюны дәвам итәләр. Район буенча уртача уныш гектардан 25 центнер тәшкил итә. Иртә таннан кичкә кадәр ашлык жыю агрегатларынын тавышы тынмый иде, бу аралар бераз ял итеп алырга янгыр булышты.



Шул ук районнын «замирлылары» очен горурлык туа. Быел монарчы булмаган уныш алынган. Аграрийларнын хезмәте, аларнын жиргә булган игътибары, кайгыртучан монәсәбәте -туендыручыга бу жирнен юмарт бvләге, кvрәсен. «За мир» ОООсы директоры Шамиль Кәрим улы Мещеров та дулкынлану кичерде. Кырда механизаторлар, Шамиль Кәримович та, vз тәгәрмәчле юлдашында алар янында; барлык проблемаларны да телефон аша тvгел, vз кvзләре белән кvреп тора. Урып-жыюнын барышын тоткарлый торган проблемалар килеп чыкса, кичекмәстән хәл итә. «Язгы салкыннар, корылык, жил комачаулауга карамастан яхшы уныш артында механизаторларнын хезмәте, туфрак эшкәртvгә дорес якын килv, чәчv-лекләрне вакытында эш-кәртv тора. - ди директор. -

Әлбәттә, хәзер дулкынланып кvккә карыйбыз. Яхшы һава торышы кирәк. Әмма топ һаваны кешеләр ясый, алардан башка техника vлгән, vсемлек чыга алмый һәм башак та олгерми.
Басуларда мул булып игеннәр олгерде. Талгын жилдә тибрәлгән башаклар шавы муллык вәгъдә итә. Хәзер аларны тvкми-чәчми жыйнап алу топ бурыч булып тора».
Чыннан да, дорес алым һәм фидакарь хезмәт кенә шундый нәтижә бирә: «Скипетр» сортлы бодай яхшы vскән, бортекләре тулы, чиста, чvпсез. Ин тыйнак исәпләvләр буенча, анын уртача унышы 30 ц/га тәшкил иткән. Ә инде 11 августка, «За мир» аграрийлары бодайны урып-жыюны тогәлләп, яровой сабан культураларын суктыруга керешкәннәр. Тик берничәконгә тәнәфес кенә ясаганнар.
Авылда яна уныш алу процессы һәрвакыт бәйрәм кебек уза. Амбардагы азык я элеваторга, я халыкка озатыла. «За мир»да ашлыкка сорау зур. Икмәк алу остенлеге, беренче чиратта, басуга vз хезмәтләрен кертvчеләр, предприятие хезмәткәрләре, жир пайлары арендага алынган пенсионерлар. Пай жиренә 2 центнер ашлыкк бушлай бирелә. Биредә бу традицияне югалтмаганнар. Ашлыкны капчыкка салып, ашыкмыйча, яхшы кәеф белән vлчиләр. Чонки икмәк – ул изге.

**Наилә НАСЫРОВА**